**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3901**
**29.07.2019**

Муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм аның Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан үтәлешен финанс белән тәэмин итү тәртибе турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

РФ Бюджет кодексының 69.2 маддәсенең 4 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 17 гыйнварындагы 153 нче карары белән расланган муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм аның Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан үтәлешен финанс белән тәэмин итү тәртибе турында нигезнамәгә, 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«9. Муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү шәһәр бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә, Башкарма комитет карары белән раслана.

Муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү күләме Башкарма комитетның финанс идарәсе тарафыннан агымдагы елның 1 декабренә кадәр срокка исәпләнә:

1) муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар, шулай ук муниципаль йөкләмәне үтәүгә бәйле, ләкин норматив чыгымнарга кертелмәгән чыгымнар нигезендә – муниципаль белем бирү оешмалары өчен;

2) индекс-дефляторны исәпкә алып, узган елгы чыгымнар нигезендә – башка муниципаль учреждениеләр өчен.

Муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү муниципаль учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән яки мондый мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы бүлеп биргән акчалар хисабына муниципаль

автономияле учреждение тарафыннан сатып алынган муниципаль мөлкәтне карап тоту чыгымнарын, салым салу объекты буларак тиешле мөлкәт, шул исәптән җир участоклары танылa торган салымнарны түләү чыгымнарын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Муниципаль автономияле учреждениегә гамәлгә куючы тарафыннан беркетелгән яки мондый мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы бүлеп биргән акчалар хисабына муниципаль автономияле учреждение тарафыннан сатып алынган күчемсез мөлкәт яки аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт гамәлгә куючының ризалыгы белән арендага бирелгән очракта, гамәлгә куючы тарафыннан мондый мөлкәтне карап тотуны финанс белән тәэмин итү гамәлгә ашырылмый.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев